| ГЛАВА<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2021е. п.г.т. Алексеевское № 18

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Сабакайка авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге Уставының 22.1 маддәсе нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2021 елның 23 декабренә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сабакайка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 08:00 сәгатьтә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Алексеевск шәһәр җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, тыл хезмәтчәннәре, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан, 18 яшькә кадәрге 3 тән артык баласы булган гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- балалар өчен уен мәйданчыклары сатып алу һәм урнаштыру;
- урамнарны һәм ял зоналарын төзекләндерү һәм яшелләндерү;
- һәйкәлләр төзү һәм төзекләндерү;
- зират территориясен карап тоту һәм төзекләндерү;

- сууткәргеч һәм канализация челтәрләрен төзү һәм реконструкцияләү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, Алексеевск ш.т.б. башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

ӘЙЕ ЮК».

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 10 көн дәвамында мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**